**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода, ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе, Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.05.2018 пгт. Рыбная Слобода № 84пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләүне тәртипкә салу һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 30 мартындагы “Бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү шартлары турында” гы 195 номерлы карары, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Билгеләргә: Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларының (алга таба – аерым оешмалар) җитәкчеләре, белгечләре һәм хезмәткәрләренең хезмәт хакы айлык вазыйфаи хезмәт хакыннан, озак еллар хезмәт иткән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмәдән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмәдән, айлык акчалата бүләкләүдән,эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, ел саен түләүле ял алганда бер тапкыр бирелә торган түләүдән, матди ярдәмнән, шулай ук законда каралган башка түләүләрдән тора. Белгечләрнең һәм хезмәткәрләрнең хезмәт хакы составына шулай ук берничә вазыйфаны берюлы башкарган өчен, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәгән өчен өстәмә түләүләр дә кертелә;

аерым оешмалар эшчеләренең хезмәт хакы айлык тариф ставкасыннан, компенсация түләүләреннән, катлаулылык һәм киеренкелек өчен тариф ставкасына айлык өстәмәдән, эш нәтиҗәләре буенча премияләрдән, ел саен түләүле ял алгандагы матди ярдәмнән, матди ярдәмнән, машина йөртүчеләргә класслылык өчен айлык өстәмәдән, берничә вазыйфаны берюлы башкарган өчен, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәгән өчен өстәмә түләүләрдән, шулай ук законда каралган башка түләүләрдән тора.

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгеч һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакы күләме муниципаль берәмлекләрнең Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән бюджет өлкәсе аерым оешмаларының структура подразделениесе җитәкчесе сәркатибенең 11 163,0 сум булган вазыйфаи хезмәт хакы күләменең кабатлысы күләмендә исәпләнә.

Татарстан Республикасы бюджетыннан финансланучы аерым учреждение эшчеләренә айлык тариф ставкалары һәм компенсация түләүләр күләме Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәре нигезендә исәпләнә.

2.Расларга:

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларының җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен (1 номерлы кушымтада бирелә);

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен (2 номерлы кушымтада бирелә);

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларның структура подразделениеләр җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен (3 номерлы кушымтада бирелә);

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларның структура подразделениеләр хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмен (4 номерлы кушымтада бирелә);

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүдәге эшчеләрнең хезмәтенә түләү разрядлары диапазонын (5 номерлы кушымтада бирелә);

3.Аерым оешмаларның җитәкчеләренә, белгечләре һәм хезмәткәрләренә билгеләргә:

1) Озак еллар хезмәт иткән өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмәне түбәндәге күләмнәрдә:

| Хезмәт стажы (…булганда) | Айлык өстәмә, % ларда |
|---|---|
| 1 дан 5 елга кадәр | 5 |
| 5 дан 10 елга кадәр | 7 |
| 10 дан 15 елга кадәр | 10 |
| 15 елдан артык | 15; |

2) эшнең катлаулы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмәне вазыйфаи хезмәт хакының 10% ы күләмендә;

3) айлык акчалата бүләкләүне вазыйфаи хезмәт хакының ике проценты күләмендә;

4) билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә эш нәтиҗәләре буенча премияләрне (премия күләме хезмәткәрнең эшчәнлек нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләме чикләнми);

5) ел саен түләүле ял алганда вазыйфаи хезмәт хакының 120% ы күләмендә елга бер тапкыр бирелә торган түләүне;

Әгәр җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә календарь ел дәвамында ел саен алына торган түләүле ял бирелмәсә, бер тапкыр бирелә торган түләү аңа бу очракта хезмәт куйган вакытына пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм шул елның декабрендә түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча;

Беренче елын эшләгән җитәкчегә, белгечкә, хезмәткәргә ел саен алына торган түләүле ял бирелгәндә бер тапкыр бирелә торган түләү календарь елда хезмәт куйган вакытына пропорциональ рәвештә исәпләнә. Хезмәт кую вакыты эшкә кергән көннән алып агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр санала.

6) билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә матди ярдәмне.

4. Белгечләргә һәм хезмәткәрләргә берничә вазыйфаны берюлы башкарган өчен, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәгән өчен өстәмә түләүне билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә төп эше буенча вазыйфаи хезмәт хакының 50% ы күләмендә билгеләргә.

5. Аерым оешмалар эшчеләренә билгеләргә:

1) эшнең катлаулы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасының 50%ына кадәр күләмдә эш урынындагы җиңел машинаны йөртүчеләргә өстәмәне исәпкә алмыйча нормага салынмаган эш көне өчен айлык тариф ставкасына өстәмә;

2) эш нәтиҗәләре буенча премияләр (премия күләме хезмәткәрнең эшчәнлек нәтиҗәләреннән чыгып билгеләнә һәм максималь күләме чикләнми);

3) ел саен алына торган түләүле ял биргәндә айлык тариф ставкасының 25% күләмендәге премияне исәпкә алып ике айлык тариф ставкасы күләмендә матди ярдәм;

Әгәр эшчегә календарь ел дәвамында ел саен алына торган түләүле ял бирелмәсә, ел саен алына торган түләүле ял бирелгәндә матди ярдәм хезмәт куйган вакытына пропорциональ рәвештә исәпләнә һәм декабрь аенда түләнә, эштән киткән очракта – соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча;

Беренче елын эшләгән эшчегә матди ярдәм ел саен алына торган түләүле ял бирелгәндә календарь елда хезмәт куйган вакытына пропорциональ рәвештә исәпләнеп түләнә. Хезмәт кую вакыты эшкә кергән көннән алып агымдагы календарь елның 31 декабренә кадәр санала.

4) билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә матди ярдәм.

5)эш урынындагы җиңел машина йөртүчеләргә түбәндәге күләмнәрдә класслылык өчен ай саен өстәмә:

1 класслы машина йөртүчеләргә – билгеләнгән айлык тариф ставкасының 25% ы күләмендә машина йөртүче сыйфатында хезмәт куйган вакыты өчен;

II класслы машина йөртүчеләргә – билгеләнгән айлык тариф ставкасының 10% ы күләмендә машина йөртүче сыйфатында хезмәт куйган вакыты өчен;

6)айлык өстәмә:

берничә вазыйфаны берюлы башкарган өчен, хезмәт күрсәтү зонасын киңәйтү һәм үзенең төп эше белән беррәттән вакытлыча булмаган хезмәткәрләрнең вазыйфаларын үтәгән өчен гамәлдәге законнар нигезендә билгеләнгән хезмәткә түләү фонды чикләрендә төп эше буенча айлык тариф ставкасының 50% ка кадәр күләмендә;

төнге вакытта (22 сәг. тән 6 сәгатькә кадәр) эшләгән өчен сәгатьлек тариф ставкасының 35% ы күләмендә;

бәйрәм һәм ял көннәрендә эшләгән өчен – икеләтелгән көнлек тариф ставкасы күләмендә;

эш урынындагы җиңел машина йөртүчеләргә нормага салынмаган эш көне өчен – айлык тариф ставкасының 50%ы күләмендә.

6.Тиешле федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларда каралганча хезмәткәрләргә башка төрле түләүләрне ясарга.

7.Аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләр һәм хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү фондын формалаштырганда вазыйфаи хезмәт хакларын түләү өчен бүленә торган средство суммаларыннан тыш түләү өчен (бер елга исәпләгәндә 12 вазыйфаи хезмәт хакыннан чыгып) түбәндәге средстволар күздә тотылуны билгеләргә:

1) озак еллар хезмәт иткән өчен айлык өстәмә – вазыйфаи хезмәт хакларының җиде проценты күләмендә;

2) эшнең катлаулы һәм киеренкелеге өчен вазыйфаи хезмәт хакына айлык өстәмә – вазыйфаи хезмәт хакларының 10%ы күләмендә;

3) эш нәтиҗәләре буенча премияләр – вазыйфаи хезмәт хакларының бер проценты күләмендә;

4) айлык акчалата бүләкләүләр - вазыйфаи хезмәт хакларының ике проценты күләмендә;

5) ел саен алына торган түләүле ял бирелгәндәге бер тапкыр түләнә торган түләүләр һәм матди ярдәм - вазыйфаи хезмәт хакларының 10 проценты күләмендә.

8. Аерым оешма эшчеләренең хезмәтенә түләү фондын формалаштырганда тариф ставкаларын түләү өчен бүленә торган средство суммаларыннан тыш (компенсация тәләүләрен исәпкә алып) түләү өчен (бер елга исәпләгәндә) түбәндәге средстволар күздә тотылуны билгеләргә:

1) эшнең катлаулы һәм киеренкелеге өчен айлык тариф ставкасына ай саен өстәмә – бер айлык тариф ставкасы күләмендә;

2) машина йөртүчеләргә класслылык, нормага салынмаган эш көне өчен – тугыз айлык тариф ставкасы күләмендә;

3)эш нәтиҗәләре өчен премияләр - өч айлык тариф ставкасы күләмендә;

4) ел саен алына торган түләүле ял бирелгәндәге матди ярдәм – айлык тариф ставкасының 25 %ы күләмендәге премияне исәпкә алып ике айлык тариф стакасы күләмендә.

9.Билгеләргә:

аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләр һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хаклары күләмнәре, шулай ук аерым оешмаларның хезмәткәрләренә айлык һәм башка түләүләр күләме сумга кадәр арттыру ягына түгәрәкләнә;

аерым оешмалар җитәкчеләре һәм белгечләренең вазыйфаи хезмәт хакларын күтәрү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакларын күтәрү өчен каралган срокларда һәм күләмнәрдә гамәлгә ашырыла;

аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакларын күтәрү Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының аналогик категория хезмәткәрләренең вазыйфаи хезмәт хакларын күтәрү сроклары һәм күләмнәрендә гамәлгә ашырыла;

әлеге карар кабул ителү белән аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүнең башка шартлары кулланылмый.

10. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны тормышка ашыру белән бәйле чыгымнарны билгеләнгән тәртиптә финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә .

11.Аерым оешмаларның җитәкчеләренә

Хезмәткәрләрнең вазыйфалары исемнәрен 1 номерлы кушымтага туры китерергә;

аерым оешмаларның хезмәткәрләренә өстәмәләр һәм башка түләүләр билгеләү турындагы элек чыгарылган актларны әлеге карар белән туры китерергә.

12.Көчен югалтуын танырга:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 сентябрендәге “Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы 216пи номерлы карарының;

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 26 мартындагы 61пи номерлы “Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 сентябрендәге “Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында”гы 216пи номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында”гы карарының.

13.Билгеләргә: карар аны рәсми рәвештә бастырып чыгаргач (халыкка игълан иткәч) көченә керә һәм 2018 елның 1 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләрен колачлый.

14. Карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”ында урнаштырырга.

5. Бу карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад мәсьәләләре буенча урынбасары Токранов В.И. ка йөкләргә.

Җитәкченең беренче урынбасары Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль
районы Башкарма комитетының
2018 елның 7 маендагы
84пи номерлы карарына
кушымта №1

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмаларының җитәкчеләре һәм белгечләренең

айлык вазыйфаи хезмәт хаклары күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык вазыйфаи хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|
| Бюджет өлкәсенә кергән оешма | |
| Оешма җитәкчесе | 25 117 |
| Оешма җитәкчесе урынбасары | 22 326 |
| Оешма составындагы идарә башлыгы | 20 094 |
| Бүлек башлыгы, җитәкче ярдәмчесе | 18 419 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 17 303 |
| Баш белгеч | 15 629 |
| Әйдәүче белгеч | 13 061 |
| I категорияле белгеч | 12 503 |
| II категорияле белгеч | 12 280 |
| Белгеч | 12 057 |

Искәрмә:

Бер үк вакытта структура подразделениесе җитәкчесе булып торган җитәкче урынбасарының айлык вазыйфаи хезмәт хакы тиңдәшле җитәкче урынбасары вазыйфасы буенча билгеләнә.

Кабул итү бүлмәсе, беренче бүлек, гомуми бүлек, канцелярия, хуҗалык бүлеге һәм башка охшаш подразделениеләрнең мөдирләренең (башлыкларының) вазыйфаи хезмәт хаклары тиешле оешманың баш, әйдәп

баручы һәм башка белгечләренең вазыйфаи хезмәт хаклары дәрәҗәсендә билгеләнә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 7 маендагы
84пи номерлы карарына
кушымта №2

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары хезмәткәрләренең

айлык вазыйфаи хезмәт хаклары күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык вазыйфаи хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор, машинкада басу бюросы мөдире, копировка-күбәйтү бюросы мөдире, инспектор, статистик, хуҗалык мөдире, склад мөдире, кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографистка, сәркатип-стенографистка, машинистка, экспедитор, сәркатип-машинистка, җитәкченең сәркатибы | 11 163 |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 7 маендагы
84пи номерлы карарына
кушымта №3

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары структура подразделениеләре җитәкчеләре һәм белгечләренең
айлык вазыйфаи хезмәт хаклары күләме

| Вазыйфаның исеме | Айлык вазыйфаи хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|

| | V<br>төркем |
|---|---|
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе | 14959 |
| Мөстәкыйль идарә (бүлек) җитәкчесе урынбасары | 14512 |
| Бүлек башлыгы | 13954 |
| Бүлек башлыгы  урынбасарыө | 13061 |
| Баш белгеч | 12280 |
| Әйдәүче белгеч | 11722 |
| I категорияле  белгеч | 11163 |
| II категорияле белгеч | 11163 |
| Белгеч | 11163 |

Искәрмә:

V төркем -.Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Буа, Алабуга, Зәй, Лениногорск, Нурлат, Чистай шәһәрләре һәм Республики Татарстан Республикасының I - IV төркемнәргә кертелмәгән башка муниципаль берәмлекләре.

Татарстан Республикасы
Балык  Бистәсе муниципаль  районы
Башкарма комитетының
2018 елның 7 маендагы
84пи номерлы карарына
кушымта №4

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль  районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалары структура подразделениеләре хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи  хезмәт хаклары күләме

| Вазыйфаларның  исемнәре | Айлык вазыйфаи хезмәт хакы, сумнарда |
|---|---|
| Архив мөдире, өлкән инспектор,  машинкада басу, копировка-күбәйтү  бюросы  мөдирләре,  инспектор, | 11163 |

| | |
|---|---|
| статистик, хуҗалык, склад мөдирләре; кассир, комендант, эш башкаручы, архивариус, стенографистка, сәркатип-стенографистка, машинистка, экспедитор, сәркатип-машинистка, җитәкченең сәркатибе | |

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының
2018 елның 7 маендагы
84пи номерлы карарына
кушымта №5

Татарстан Республикасының бюджет өлкәсендәге хезмәткәрләргә хезмәт хакы түләү буенча Бердәм тариф челтәренә кермәгән Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар эшчәнлегенә хезмәт күрсәтүдәге эшчеләрнең хезмәтенә түләү разрядлары диапазоны

| Һөнәрнең исеме | Хезмәткә түләү разряды |
|---|---|
| Гардеробта эшләүче, территорияне җыештыручы, курьер | 1 |
| Каравылчы (вахтер), җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы, лифтер, кладовой мөдире, йөк төяүче (бушатучы) | 1 - 2 |
| Электрон-хисаплау һәм хисаплау машиналары операторы,биналарга комплекслы хезмәт күрсәтү һәм ремонт үткәрүче эшче | 2 - 4 |
| Копировка һәм күбәйтү машиналары операторы | 2 - 3 |
| Җиңел машина йөртүчесе | 4 - 5 |

Искәрмә:

Җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручыларга икенче разряд тариф ставкасы җитештерү биналарын, шул исәптән җитештерү калдыкларын, санузелларны һәм җәмәгать бәдрәфләрен җыештырган өчен билгеләнә.

Машина йөртүчеләргә бишенче разряд тариф ставкасы җиңел машиналарның икенче-өченче тибында эшләгән өчен, шулай ук техник хезмәт күрсәтүче махсуслашкан хезмәт күрсәтү службасы булмаган очракта машиналарга ремонт үткәрү һәм техник хезмәт күрсәтү буенча эшләрнең бөтен комплексын башкарган өчен билгеләнә.